КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1448

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 771 нче карары белән расланган Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюдже-тыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 771 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июль, 729 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә

ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның өченче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин